РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ
Нижнекамского муниципального района

423570, г.Нижнекамск, пр.Строителей,12
факс (8555) 41-70-00, тел.42-41-41

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Түбән Кама муниципаль районы
СОВЕТЫ

423570, Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр пр., 12
факс (8555) 41-70-00, тел.42-41-41

РЕШЕНИЕ КАРАР

№ 49 2021 елның 1 сентябре

## Татарстан Республикасы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган Түбән Кама муниципаль районының аерым бюджет өлкәсе оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү турында

Социаль гарантияләрне тәэмин итү һәм бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләүне тәртипкә салу максатыннан, Түбән Кама муниципаль район Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Билгеләргә:

Татарстан Республикасы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым бюджет өлкәсе оешмалары (алга таба - аерым оешмалар) җитәкчеләре, белгечләре һәм хезмәткәрләренең хезмәт хакы айлык вазыйфаи окладыннан, тиешле еллар эшләгән өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмәдән, кыенлык һәм киеренкелек өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмәдән, эш нәтиҗәләре буенча айлык акчалата бүләкләү, премияләрдән, еллык түләүле отпуск алганда бер тапкыр бирелә торган түләүдән, матди ярдәмнән, шулай ук законнар нигезендә башка түләүләрдән тора. Белгечләрнең һәм хезмәткәрләрнең хезмәт хакы составына шулай ук һөнәрләрне берләштергән өчен өстәмә түләүләр, хезмәт күрсәтү зоналарын киңәйтү һәм үзләренең төп эше белән беррәттән вакытлыча эшләмәүче хезмәткәрләрнең вазыйфаларын үтәү кертелә;

аерым оешмалар хезмәткәрләренең хезмәт хакы айлык тариф ставкасыннан, компенсация түләүләреннән, эшнең катлаулылыгы һәм киеренкелеге өчен айлык тариф ставкасына айлык өстәмәдән, эш нәтиҗәләре буенча премияләрдән, еллык түләүле отпуск алганда матди ярдәмнән, матди ярдәмнән, класс өчен машина йөртүчеләргә айлык өстәмә түләүләр, һөнәрләрне берләштергән өчен өстәмә түләүләр, хезмәт күрсәтү зоналарын киңәйтү һәм үзләренең төп эше белән беррәттән вакытлыча булмаган хезмәткәрләрнең бурычларын үтәүдән, шулай ук законнар нигезендә башка түләүләрдән тора;

аерым оешмалар җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләме Татарстан Республикасы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсе аерым оешмасының структур бүлекчәсе җитәкчесе секретаренең 11 498 сумны тәшкил итә торган вазыйфаи оклады күләменә нисбәттә исәпләнә;

аерым учреждениеләрнең эшчеләренә айлык тариф ставкалары һәм компенсация түләүләре күләме Татарстан Республикасы бюджет өлкәсе оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре нигезендә исәпләнә.

2. Расларга:

1 нче кушымта нигезендә Татарстан Республикасы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган Түбән кама муниципаль районы аерым бюджет өлкәсе оешмалары җитәкчеләре һәм белгечләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен исәпләгәндә кулланыла торган нисбәт коэффициенты;

2 нче кушымта нигезендә Татарстан Республикасы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган Түбән Кама муниципаль районы бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен исәплəгәндә кулланыла торган нисбәт коэффициенты;

3 нче кушымта нигезендә Татарстан Республикасы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган Түбән Кама муниципаль районы бюджет өлкәсенең аерым оешмалары эшчәнлегенә хезмәт күрсәтү белән шөгыльләнүче эшчеләр хезмәтенә түләү разрядлары диапазоны;

4 нче кушымта нигезендә хезмәт көне нормага салынмаган шартларда эшләгән өчен Татарстан Республикасы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган Түбән Кама муниципаль районы аерым бюджет өлкәсе оешмалары хезмәткәрләренә айлык компенсация түләүләрен билгеләү тәртибе;

5 нче кушымта нигезендә мактаулы исемнәр, күкрәк яки мактау билгеләре өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә түләү билгеләү тәртибе.

3. Аерым оешмалар җитәкчеләренә, белгечләренә һәм хезмәткәрләренә билгеләргә:

1) тиешле еллар эшләгән өчен вазыйфаи окладка түбәндәге күләмнәрдә айлык өстәмә:

| Эш стажы | Айлык өстәмә түләү, процент |
|---|---|
| 1 дән 5 елга кадәр | 5 |
| 5 тән 10 елга кадәр | 7 |
| 10 нан 15 елга кадәр | 10 |
| 15 елдан күбрәк | 15 |

Аерым оешмаларның җитәкчеләре, белгечләре һәм хезмәткәрләренең эш стажына күрсәтелгән затларның Түбән Кама муниципаль районы һәм Түбән Кама шәһәре муниципаль учреждениеләрендә хезмәт эшчәнлеге чорлары кертелә;

2) вазыйфа окладының ун проценты күләмендә эшнең катлаулылыгы һәм киеренкелеге өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә;

3) вазыйфаи окладның ике проценты күләмендә айлык акчалата бүләкләү;

4) хезмәт өчен түләүнең билгеләнгән фонды чикләрендә эш нәтиҗәләре буенча премияләр (агымдагы финанс елында район бюджетын төгәлләштерүне исәпкә алып). Премиянең күләме хезмәткәр эшчәнлеге нәтиҗәләреннән чыгып билгеләнә һәм максималь күләм белән генә чикләнми.

Башка премияләр хезмәт хакының биш айлык уртача күләменнән артмаска тиеш. Премия ай саен, квартал саен, бер ел өчен түләнә, шулай ук бәйрәм һәм юбилей даталарына туры китерелергә мөмкин.

Премия күләмен исәпләгәндә, ел саен түләнә торган отпуск алганда бер тапкыр бирелә торган түләү, матди ярдәм, квартал һәм еллык премияләр, хезмәткәрнең административ һәм уку ялында булу вакыты, вакытлыча эшкә сәләтсез чоры исәпкә алынмый;

5) хезмәткәрләргә аена өч вазыйфаи окладтан артмаган күләмдә өстәмә компенсация түләүләре;

6) Түбән Кама муниципаль район Советының «Түбән Кама муниципаль район Советының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 3 февралендәге 8 номерлы карарының 3 пункты нигезендә, РФ Президентының «Дәүләт социаль сәясәтен гамәлгә ашыру чаралары турында» 2012 елның 7 маендагы 597 номерлы Указы нигезендә, «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым бюджет өлкәсе оешмалары хезмәткәрләренә түләү шартлары турында» 2018 елның 30 мартындагы 195 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарының 6 пункты нигезендә, әлеге карарның 7 пункты белән, хезмәткәрләрнең хезмәт хакын хезмәт өчен түләү шартларына күчү вакытына гамәлдә булган хезмәткә түләү системасы нигезендә түләнә торган хезмәт хакы дәрәҗәсенә җиткерү максатларында, хезмәткәрләргә аена өч вазыйфаи окладтан артмаган күләмдә өстәмә компенсация түләве кертергә.

4. Белгечләргә һәм хезмәткәрләргә һөнәрләрне берләштергән, хезмәт күрсәтү зоналарын киңәйтү һәм үз төп эше белән беррәттән вакытлыча эшләмәүче хезмәткәрләрнең йөкләмәләрен үтәгән өчен билгеләнгән хезмәт өчен түләү фонды чикләрендә төп эш буенча хезмәт хакыннан 50% ка кадәр күләмдә өстәмә түләү билгеләргә.

5. Эш бирүче карары буенча яңа коронавирус йогышы таралуны кисәтүгә (шул исәптән лаборатор анализлар үткәрүгә) бәйле чыгымнарны кайтарганда, шулай ук хезмәткәрнең һәм аның якын туганнарының каты авыруы, вафат булуы һәм башка бәхетсезлек очракларында матди ярдәм түләнә ала.

Матди ярдәм түләү хезмәткәрнең гаризасы нигезендә, хезмәткәрнең айлык хезмәт хакыннан артмаган күләмдә башкарыла.

Зур күләмдә матди ярдәм Түбән Кама муниципаль районы Башлыгы белән килешенеп түләнә ала.

6. Аерым оешмаларның эшчеләренә билгеләргә:

1) нормага салынмаган эш көне өчен хезмәт җиңел автомобильләре йөртүчеләренә өстәмә түләүне исәпкә алмыйча, айлык тариф ставкасының 50 проценты күләмендә эшнең катлаулылыгы һәм киеренкелеге өчен айлык тариф ставкасына айлык өстәмә түләү;

2) эш нәтиҗәләре буенча премияләр (премия күләме хезмәткәр эшчәнлеге нәтиҗәләреннән чыгып билгеләнә һәм максималь күләм белән чикләнми);

3) айлык тариф ставкасының 25 проценты күләмендә премияне исәпкә алып, ике айлык тариф ставкасы күләмендә еллык түләүле отпуск биргәндә матди ярдәм;

4) түбәндәге күләмнәрдә хезмәт һәм җиңел автомобиль йөртүчеләргә класс өчен айлык өстәмә түләү:

I класслы машина йөртүчеләргә - машина йөртүче сыйфатында эшләгән вакыт өчен билгеләнгән айлык тариф ставкасының 25 проценты,

II класслы машина йөртүчеләргә - машина йөртүче сыйфатында эшләгән вакыт өчен билгеләнгән айлык тариф ставкасының 10 проценты;

5) ай саен өстәмә түләү:

һөнәрләрне берләштергән, хезмәт күрсәтү зоналарын киңәйткән һәм үзенең төп эше белән беррәттән вакытлыча эшләми торган хезмәткәрләрнең

вазыйфаларын да башкарган өчен - хезмәт өчен түләү фонды чикләрендә гамәлдәге законнар нигезендә төп эш буенча хезмәт хакыннан 50% ка кадәр күләмдә;

төнге вакытта эшләгән өчен (22 сәгатьтән 6 сәгатькә кадәр) - сәгатьле тариф ставкасының 35 проценты күләмендә;

бәйрәм һәм ял көннәрендә эшләгән өчен - икеләтә көнлек тариф ставкасы күләмендә;

нормага салынмаган эш көнендә хезмәт җиңел автомобильләрен йөртүчеләргә - айлык тариф ставкасының 50 проценты күләмендә.

7. Хезмәткәрләргә федераль законнарда, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларда каралган башка түләүләр башкарырга.

8. Аерым оешмалар җитәкчеләре, белгечләре һәм хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү фондын формалаштырганда, вазыйфаи окладларны түләү өчен җибәрелә торган акчалардан тыш, түләү өчен түбәндәге акчалар каралуын билгеләргә (бер елга исәпләнгән 12 вазыйфаи окладтан чыгып):

1) тиешле еллар эшләгән өчен айлык өстәмә - вазыйфаи окладларның 7 проценты күләмендә;

2) эшнең катлаулылыгы һәм киеренкелеге өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә - вазыйфаи окладларның 10 проценты күләмендә;

3) эш нәтиҗәләре буенча премияләр - вазыйфаи окладларның 1 проценты күләмендә;

4) айлык акчалата бүләкләү - вазыйфаи окладларның 2 проценты күләмендә;

5) еллык түләүле отпуск биргәндә һәм матди ярдәм күрсәткәндә бер тапкыр бирелә торган түләү - вазыйфаи окладларның 10 проценты күләмендә;

6) нормага салынмаган эш көне шартларында эшләгән өчен айлык компенсация түләве – вазыйфаи окладка карата 110 проценттан артмаган күләмдә.

9. Аерым оешмалар эшчеләренең хезмәт өчен түләү фондын формалаштырганда тариф ставкаларын түләү өчен җибәрелә торган акчалардан (компенсация түләүләрен исәпкә алып) тыш түләү өчен түбәндәге акчалар каралуын билгеләргә (бер елга исәпләгәндә):

1) эшнең катлаулылыгы һәм киеренкелеге өчен айлык тариф ставкасына айлык өстәмә түләү - бер айлык тариф ставкасы күләмендә;

2) машина йөртүчеләргә класслык өчен, нормага салынмаган эш көне өчен айлык өстәмә түләү - тугыз айлык тариф ставкасы күләмендә;

3) эш нәтиҗәләре буенча премияләр - өч айлык тариф ставкасы күләмендә;

4) еллык түләүле отпуск биргәндә матди ярдәм - айлык тариф ставкасының 25 проценты күләмендә премияне исәпкә алып, ике айлык тариф ставкасы күләмендә.

10. Билгеләргә:

аерым оешмалар җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары, шулай ук аерым оешмалар хезмәткәрләренә айлык һәм башка түләүләр күләме тулы сумга кадәр арттыру ягына түгәрәкләнергә тиеш;

аерым оешмалар җитәкчеләренең һәм белгечләренең вазыйфаи окладларын арттыру Түбән Кама муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын арттыру өчен каралган күләмнәрдә һәм срокларда гамәлгә ашырыла;

аерым оешмалар хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын арттыру Түбән Кама муниципаль районы җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең шундый ук категорияләренең вазыйфаи окладларын арттыру өчен каралган күләмнәрдә һәм срокларда гамәлгә ашырыла.

11. Үз көчен югалткан дип танырга:

Түбән Кама муниципаль районы Советының «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым бюджет өлкәсе

оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү турында» 2008 елның 22 февралендәге 13 номерлы карары;

Түбән Кама муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган Түбән Кама муниципаль районы аерым бюджет өлкәсе оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү турында» 2018 елның 11 апрелендәге 31 номерлы карары.

12. Әлеге карар Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф, мәктәпкәчә белем бирү, мәдәният, яшьләр эшләре, физик культура һәм спорт идарәләренә буйсынучы, үз эшчәнлекләрен мәгариф өлкәсендә (шул исәптән мәгариф учреждениеләрен методик тәэмин итү буенча структур бүлекчәләр), мәдәният, яшьләр эшләре һәм физик культура һәм спорт өлкәсендә гамәлгә ашыручы, шулай ук «Гражданнар оборонасы, гадәттән тыш хәлләр, янгын куркынычсызлыгы һәм Түбән Кама муниципаль районы су объектларында кешеләр куркынычсызлыгы идарәсе» МКУ, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы «Мәгариф үзәге» МБУ, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы «Мәктәпкәчә белем бирү үзәге» МБУ, «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Яшьләр эшләре үзәге» МБУ, «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы физик культура һәм спорт үзәге» МБУ һәм «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы мәдәният учреждениеләренә бухгалтерлык хезмәте күрсәтү үзәге» МБУ учреждениеләре хезмәткәрләренә карата кулланылмый дип билгеләргә. Әлеге категория хезмәткәрләрнең хезмәт хакын җайга салу Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының муниципаль хокукый актлары белән гамәлгә ашырыла.

13. Түбән Кама муниципаль районы Советының бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлеге, Түбән Кама муниципаль районы җирле үзидарә органнарына әлеге карарның үтәлешен тәэмин итәргә.

14. «Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең бюджет һәм финанслар департаменты» муниципаль казна учреждениесенә әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанслауны тәэмин итәргә.

15. Җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны Түбән Кама муниципаль районы Уставы белән билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

16. Әлеге карар 2021 елның 1 сентябреннән барлыкка килгән мөнәсәбәтләргә кагыла.

17. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны социаль-икътисадый үсеш, бюджет-финанс мәсьәләләре һәм муниципаль милек буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Түбән Кама муниципаль
районы Башлыгы

А.Р.Метшин

Түбән Кама муниципаль район Советының
2021 елның 1 сентябрендәге
49 номерлы карарына
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган Түбән Кама муниципаль районы аерым бюджет өлкәсе оешмалары җитәкчеләре һәм белгечләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен исәпләгәндә кулланыла торган нисбәт коэффициенты

| Вазыйфа исеме | Вазыйфаи окладлар күләмен исәпләгәндә кулланыла торган нисбәт коэффициентлары (III төркем) |
|---|---|
| Оешма, мөстәкыйль идарә (бүлек) җитәкчесе, контроль-хисап палатасының баш инспекторы | 1,36 |
| Оешма, мөстәкыйль идарә (бүлек) җитәкчесе урынбасары | 1,32 |
| Идарә составындагы бүлек җитәкчесе, баш архитектор, контроль-хисап палатасы инспекторы | 1,27 |
| Бүлек җитәкчесе урынбасары | 1,21 |
| Баш белгеч, бухгалтер, аналитик, архитектор, ярдәмче | 1,15 |
| Әйдәп баручы белгач | 1,09 |
| I категорияле белгеч | 1,02 |
| II категорияле белгеч | 1,01 |
| Белгеч, техник-программист | 1,00 |

Түбән Кама муниципаль
районы Башлыгы урынбасары А.В.Умников

Түбән Кама муниципаль район
Советының
2021 елның 1 сентябрендәге
49 номерлы карарына
2 нче кушымта

Татарстан Республикасы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган Түбән кама муниципаль районы аерым бюджет өлкәсе оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен исәпләгәндә кулланыла торган нисбәт коэффициенты

| Вазыйфа исеме | Коэффициент |
|---|---|
| Архив мөдире, өлкән инспектор, машинкада басу бюросы мөдире, күчермә - күбәйтү бюросы мөдире, инспектор, статистик, хуҗалык мөдире, склад мөдире, кассир, комендант, эш башкаручы, архивариус, стенографист, секретарь-стенографист, машинкада басучы, экспедитор, секретарь-машинкада басучы, җитәкче секретаре | 1,0 |

Түбән Кама муниципаль
районы Башлыгы урынбасары А.В.Умников

Түбән Кама муниципаль район Советының
2021 елның 1 сентябрендәге
49 номерлы карарына
3 нче кушымта

Татарстан Республикасы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган Түбән Кама муниципаль районы бюджет өлкәсенең аерым оешмалары эшчәнлегенә хезмәт күрсәтү белән шөгыльләнүче эшчеләр хезмәтенә түләү разрядлары диапазоны

| Һөнәр исеме | Хезмәт өчен түләү разряды |
|---|---|
| Гардеробчы, ишегалды җыештыручы, курьер | 1 |
| Каравылчы (вахтер), җитештерү һәм хезмәт биналарын җыештыручы, лифтер, кладовщик, йөк төяүче | 1-2 |
| Электрон-исәпләү һәм исәпләү машиналары операторы, комплекслы хезмәт күрсәтү һәм биналарны ремонтлау буенча эшче | 2-4 |
| Күчермә һәм күбәйтү машиналары операторы | 2-3 |
| Җиңел автомобиль йөртүче | 4-5 |

Искәрмә:

Җитештерү һәм хезмәт урыннарын җыештыручыларга икенче разрядлы тариф ставкасы җитештерү биналарын, шул исәптән җитештерү калдыкларын, санузелларны һәм җәмәгать бәдрәфләрен җыештыру эшләрен башкарганда билгеләнә.

Машина йөртүчеләргә бишенче разрядлы тариф ставкасы ике-өч типтагы җиңел автомобильләрдә эшләгәндә, шулай ук автомобильләргә техник хезмәт күрсәтү махсус хезмәте булмаган очракта, автомобильне ремонтлау һәм техник хезмәт күрсәтү буенча бөтен эш комплексын башкарганда билгеләнә.

Түбән Кама муниципаль
районы Башлыгы урынбасары А.В.Умников

Түбән Кама муниципаль район
Советының
2021 елның 1 сентябрендәге
49 номерлы карарына
4 нче кушымта

Хезмәт көне нормага салынмаган шартларда эшләгән өчен
Татарстан Республикасы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча
бердәм тариф челтәре кагылмый торган Түбән Кама муниципаль районы аерым
бюджет өлкәсе оешмалары хезмәткәрләренә айлык компенсация түләүләрен билгеләү
тәртибе

1. Хезмәт көне нормага салынмаган шартларда эшләгән өчен компенсация түләү эш бирүченең локаль хокукый акты белән раслана торган нормага салынмаган эш көне булган хезмәткәрләр исемлегенә кертелгән хезмәткәрләргә бирелергә мөмкин.

2. Хезмәт килешүендә хезмәткәргә нормага салынмаган эш көне билгеләү шарты каралырга тиеш.

3. Хезмәт көне нормага салынмаган шартларда хезмәткәрне эшкә җәлеп итү эш бирүченең язмача яки телдән күрсәтмәсе буенча тормышка ашырыла.

4. Нормага салынмаган көн шартларында компенсация түләүләрен билгеләү хезмәт өчен түләүнең гамәлдәге системасы нигезендә башкарыла торган өстәмә түләүләргә бәйле түгел.

5. Хезмәт көне нормага салынмаган шартларда эшләгән өчен айлык компенсация түләү күләме вазыйфаи окладның 65 проценты күләмендә билгеләнә.

6. Өстәмә түләү билгеләү турындагы карар эш бирүче тарафыннан кабул ителә. Өстәмә түләү ай саен башкарыла һәм хезмәт хакы белән бергә түләнә.

Түбән Кама муниципаль
районы Башлыгы урынбасары А.В.Умников

Түбән Кама муниципаль район
Советының
2021 елның 1 сентябрендәге
49 номерлы карарына
5 нче кушымта

Мактаулы исемнәр, күкрәк яки мактау билгеләре өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә түләү билгеләү тәртибе

1. Мактаулы исемнәр өчен вазыйфаи окладка өстәмә билгеләү өчен нигез булып аерым оешмаларның җитәкчеләрендә, белгечләрендә, хезмәткәрләрендә, эшчеләрендә Татарстан Республикасының мактаулы исеме, Россия Федерациясенең тиешле документ белән расланган күкрәк яисә мактау билгесе булу тора. Айлык өстәмә түләү күләме вазыйфаи окладка карата 10% күләмендә билгеләнә.

2. Татарстан Республикасының күкрәк яисә мактау билгеләре өчен вазыйфаи окладка өстәмә билгеләү өчен нигез булып аеры оешмалар җитәкчеләрендә, белгечләрендә, хезмәткәрләрендә, эшчеләрендә тиешле документ белән расланган күкрәк яисә мактау билгесе булу тора. Айлык өстәмә түләү күләме әлеге кушымтаның 1 пунктында күрсәтелгән күләмнең икедән бер өлеше күләмендә билгеләнә.

3. Берничә нигез буенча аны алу хокукына ия затка өстәмә түләү аның теләге буенча бер нигез буенча билгеләнә.

Түбән Кама муниципаль
районы Башлыгы урынбасары А.В.Умников